СОВЕТ БЕРЕЗКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район,
село Березка, ул. Новостройка, 15А

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЕНЛЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Каенлык авылы, Новостройка ур.15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«20» июнь 2019 ел** **№ 10**

**«Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җирлектә яшәүче һәм аз керемле гражданнарга торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм карауны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 44 номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 14нче маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14нче маддәсе, Каенлык авыл җирлеге Уставы нигезендә, Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

-«Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җирлектә яшәүче һәм аз керемле гражданнарга торак урыннары белән тәэмин итү, муниципаль торак фондын төзүне һәм карауны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында» 2017 елның 27 ноябрендәге 44 номерлы карарын ;

-«Биектау муниципаль районының Каенлык авыл җирлеге советы 2017 елның 27 ноябрендәге 44 номерлы карарына «Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарына җирлектә яшәүче һәм аз керемле гражданнарны торак урыннары белән тәэмин итү буенча Каенлык авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары вәкаләтләре өлешен гамәлгә ашыру турында, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыру, торак төзелеше өчен шартлар тудыру, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турында» 2018 елның 30 апрелендәге 14 номерлы карарын.

2. Әлеге карар Биектау муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан ителергә тиеш: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru -Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Үтәлешен контрольдә тотам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы И.И.Гатауллин